ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д.52, с.Старое Чурилино, Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

# КАРАР

**2019 ел, « 22 » август** **№ 9**

**Иске Чуриле авыл җирлегенен 2016 елның 27 декабрендәге «Муниципаль мәгълүмат системаларының эшчәнлеге һәм алардан файдалану тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында "**

**25 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2006 елның 27 июлендәге "Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны саклау турында”149-ФЗ номерлы федераль законга, 2013 елның 5 апрелендәге “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар,эшләр, хезмәт күрсәтүләр, сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында“ 44-ФЗ номерлы федераль законның 4 нче статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 28 ноябрендәге "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр, сатып алу өлкәсендә төбәк һәм муниципаль мәгълүмат системаларына бердәм таләпләр турында " 1091 номерлы карарына яраклаштыру максатыннан Иске Чуриле башкарма комитеты КАРАР бирә:

1. Татарстан республикасы Арча муниципаль районы “Иске Чуриле авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең муниципаль мәгълүмат системаларының эшчәнлеге һәм алардан файдалану тәртибе турындагы Арча шәһәр башкарма комитетының 2016 елның 27 декабрендәге «Муниципаль мәгълүмат системаларының эшчәнлеге һәм алардан файдалану тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында" 25 нчы номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.7 пунктының 2 пунктчасының 5 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 3.7 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

“ 3) контракт системасы турында гамәлдәге Федераль законда каралган электрон документларга кул кую өчен көчәйтелгән квалификацияле электрон имза (алга таба - көчәйтелгән электрон имза) куллану»;

1.3.3.7 пунктының 4 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;